Минзәлә гимназиясе укучылары газетасы

# ЯШЬЛЕК

Январь-февраль 2026

## Бу санда:

2 - 3 нче битләр – “Безнең горурлык”

4-6 нчы битләр – укучылар иҗаты

7 нче бит- фотоконкурс

8 нче бит- “Безнең йолдыз” рубрикасы

9-11 нче битләр – гимназия сулышы

**Кадерле укучылар, хөрмәтле ир-егетләребез, әти-бабаларыбыз!**




23 февраль — Ватанны саклаучылар көне – батырлык, намус һәм кыюлык көне белән сезне ихластан котлыйбыз. Бүгенге бәйрәм көчле рухлылык, ир-егетләрнең кыюлык, намус һәм абруй шикелле сыйфатларга ия булуларын тагын бер кат раслый торган тантана.

Туган илгә һәм үз халкыңа хезмәт итү ул, туган илен чын күңелдән сөюче гражданнарның һәрчак иң югары максаты булды һәм шулай ук булып калса иде. Сезгә һәм якыннарыгызга тыныч күк йөзе, ныклы сәламәтлек, бәхет-шатлык, рухи һәм матди байлык, һәр эшегездә бары тик уңышлар гына телибез. Һәрвакыт шулай, авырлыклардан курыкмаучы, авыр минутларда үз җилкәсен куярга әзер торучы чын ир-егетләр булып калыгыз. Сәламәтлек ышанычлы юлдашыгыз булсын! Максатларыгызга ирешү, хыялларызны тормышка ашыру юлында бернинди киртәләр һәм кыенлыклар очрамасын. Бәйрәмегез белән!




**_Безнең горурлык!!!_**




10 нчы сыйныф укучысы Бокова Софья математикадан «Олимпка юл» олимпиадасында призер булды! Бу житди казаныш - тырыш хезмәт, максатчанлык һәм фән белән тирән кызыксыну нәтиҗәсе. Софья бик яхшы белемнәрен һәм стандарт булмаган фикерләүләрен күрсәтте, безнең мәктәпне ярышларда лаеклы тәкъдим итте. Укучыларны әзерләүгә көч һәм профессионализм салган, аларны яңа казанышларга рухландырган һәм математика потенциалын ачарга ярдәм иткән педагог Газизуллина Әлфия Хәсән кызына  чын күңелдән рәхмәт белдерәбез.




Республика дәрәҗәсендә тагын искиткеч уңыш: 8 нче сыйныф укучысы Шиһапова Камилә экология буенча Бөтенроссия олимпиадасының республика турында мактаулы призлы урын яулады! Камилә югары әзерлек дәрәҗәсен күрсәтте, биремнәрнең теоретик өлешен бик әйбәт үтәде. Гимназиянең биология укытучысы Миңлегареева Лилия Владимировна җитәкчелегендә башкарылган тикшеренү эшләрен бик оста тәкъдим итте һәм яклады. Тәҗрибәле педагогның остазы һәм укучының хезмәт сөючәнлеге уңыш формуласына әверелде, ул зур нәтиҗә иреште. Камилә белән Лилия Владимировнаны лаеклы призлы урыннары белән чын күңелдән котлыйбыз! Камиләгә бетмәс-төкәнмәс энергия, яңа фәнни ачышлар телибез!



Олимпиадада берьюлы өч җиңү. Гимназиябезнең өч талантлы укучысы татар теле олимпиадасының республика турында үзләрен бик яхшы күрсәттеләр һәм призлы урыннар яуладылар. Җиңүчеләрнең исемнәрен зур горурлык белән атыйбыз: Гарипова Нәргизә, Галиева Язгөл, Галиев Камилә. Бу күренекле нәтиҗә - тырыш хезмәт, туган телне тирән ярату һәм тырышып әзерләнү нәтиҗәсе. Кызларның остазларына: Заһриева Гөлнара Рөстәм кызына һәм Галиева Лилия Альберт кызына аерым рәхмәт белдерәбез. Нәкъ менә педагогларның профессиональ җитәкчелеге, аларның сабырлыгы һәм эшкә бирелгәнлеге нәтиҗәсендә укучыларыбыз үзләренең потенциалын ача алдылар һәм гимназияне республика дәрәҗәсендә лаеклы тәкъдим иттеләр. Чын күңелдән Нәргизә, Язгөл һәм Камиләне лаеклы җиңүләре белән котлыйбыз! Сезнең казанышларыгыз - бөтен гимназиянең горурлыгы!!!



Безнең укучылар яңадан бөтен төбәккә үзләренең нәрсәгә сәләтле булуларын күрсәттеләр! 8 нче сыйныфтан Шиһапова Камилә һәм 10 нчы сыйныфтан Бокова Софья рус теле буенча республика олимпиадасының чын йолдызлары булдылар! Бу искиткеч нәтиҗә безнең кадерле укытучыбыз Викулова Олгьа Сергеевна хезмәтеннән башка мөмкин түгел. Нәкъ менә аның сабырлыгы, зирәклеге һәм балаларга ышанычы мондый гаҗәеп казанышны бүләк итте. Кызларыбызның уңышлары яраткан гимназиябезнең башка укучылары өчен ачык үрнәк булсын! Без сезгә сокланабыз, кызлар, сездән яңа якты җиңүләр көтәбез!



**Озак еллар барган Җиңү!**

11 сыйныф укучысы Хәсәнов Инсафны чын күңелдән рус әдәбияты буенча олимпиаданың республика этабы призеры исеме белән котлыйбыз! Бу бүләк-уңыш кына түгел, ә озак һәм җентекле эш нәтиҗәсе. Инсаф үз сүзендә нык тору һәм белемгә кызыксынуның һәрвакыт уңышка китергәнен исбатлады. Без аңа җиңүгә омтылышы өчен рәхмәт белдерәбез, шулай ук укытучысы һәм остазы Ибраһимова Фәнилә Гыйльмулла кызына юнәлеш биргәне, ышанганы һәм алга барырга булышканы өчен зур рәхмәт әйтәбез. Сезгә яңа казанышлар һәм якты җиңүләр телибез!

## *Яшь шагыйрьләр һәм язучыларның Бөтенрәсәй “Илһам” конкурсына укучылар иҗаты*



**Тамаша**

Декабрьнең уртасында
Яңгыр ява шыбырдап.
Иртән-яңгыр, кичен –салкын,
Юллар каткан шыгырдап.
Агач башындагы чыпчык
Нидер чукып маташа.
Карга чумган бөҗәкләр дә
Нидер эзли, тамаша!
Ап-ак болыт арасына
Карга кереп югала.
Шул болытларга утырып

Күккә таба юл яра.
Баһаветдинов Радель

*****

**Дөнья матур, дөнья киң!**

Дөнья тулы якты матурлыктан
Күрә белсәң һәрбер адымда.
Күк йөзендә йөзгән болытларга
Һәм таңнарның алсу нурын да.
Яшәү - үзе зур бер могҗиза ул,
Һәр мизгелнең белсәк кадерен.
Күңелләргә игелекләр җыйсак,
Табарбыз без бәхет ачкычын.
Телебезнең чишмәдәй сафлыгы
Җырлар булып күккә ашар ул...
Яхшы уйлар, изге гамәл белән
Дөнья тизрәк чәчәк атар ул.
Бу дөньяның барлык матурлыгы,
Күңелләрдән башлана бит ул.
Матур уйлап, матур яши белсәк,
Бәхет юлы һәрчак ачык ул.
Гараев Альберт

*****

**Кыш**

Яратам мин кыш айларын,
Дулап карлар яуганын.
Чана тартып, кар тавыннан
Көрткә кереп чумганым...
Яка асларына кереп,
Муеныма тулганын.
Айсыз төннәрдә дә кышын
Бигрәк якты булганын.
Яңа елда кыш бабайны,
Ничек көтеп алганым.
Кыш булмаса, кыш бабайны
Ничек күрер идем мин?
Шәрифуллин Таһир

*****

**Сабантуй**

Сабантуй -  күңелле бәйрәм,
Халык җырлый, шатлана.
Яхшы бүләкләр алырга
Балалар уенга чаба.
Озак күрешмәгән дуслар,
Туганнар җыелып кайта.
Әби-бабайның өйләре
Шау-гөр килә шул чакта.
Җырлы-биюле уеннар,
Иң кызыклысы- көрәш.
Тәкә алып кайткан егет-
Һәр кешегә дә үрнәк.
Элек-электән булган бит.
Сабантуй бәйрәмнәре.
Йолаларны онытмыйча
Һәр ел үткәрик әле!
Шәмсиев Адель

*****

**Кыш**

Менә салкын кыш җитте.
Кошлар көньякка китте.
Елгада бозлар катты.
Кояш болытка качты.
Кыш килгәнгә сөенеп,
Тау битендә балалар.
Кар-бураннар уйнатып,
Чана-чаңгы шуалар.
Шатлыклы авазлардан,
Гөрләп тора тирә як.
Имин булсын дөньялар,
Матур үтсен балачак.
Мостаева Эльвира

*****

**Туган телем**

Кояш чыкты иртәдән,
Көлә күкләр, җирләр дә.
Якты көнгә сөенеп,
Уяна бит гөлләр дә.
Җил исә болыннарда,
Чәчәк ата гөлләр дә.
Кошлар сайрый моңланып,
Бәхет тулы көннәрдә.
Туган телем-матур тел,
Йөрәгемдә яши ул.
Шигырь булып агыла
Күңелемне назлый ул.
Мөбәрәкшин Рамазан

*****

**Туган ягым матурлыгы**

Ап-ак карлар бөтерелеп,
Әкрен генә җиргә төшә.

Әни белән җиләк җыйган
Ямьле җәйләр искә төшә.
Чәчәкле җәйге болында
Күбәләкләр очалар.
Җиләкләргә утырып,
Канатларын ачалар.
Туган якның матурлыгын,
Күреп шатлана бала.
Күбәләктәй канатланып,
Әйтерсең очып бара.

Гәрәева Нәргизә

*****

**Кәефем өйдә калган...**

Кайтасым килә өйгә...
Бу уку миңа нигә?
Берни эшлисем килми,
Беркем хәлемне белми.
Әни "кайт" дисә иде,
Артымнан килсә иде...
Елыйсым килә кебек,
Тәмам төштем мин җебеп...
Дәфтәрем бар, китабым,
Ни кирәк, дисез, тагын?
Хәлем чыннан да яман
Кәефем өйдә калган.

Талипова Язилә

****

**Энәсез керпе маҗаралары**

Урманда керпе гаиләсендә бер бәләкәй керпе туган, ләкин аның энәләре булмаган. Әнисе: "Яхшы эшләр эшләсәң, энәләрең тиз, куе булып үсәрләр",- дигән.

Менә керпе урман буйлап изге эшләр эзләргә чыгып киткән. Бара икән, аның каршына чыркылдап чыпчык очып чыккан:

- Керпекәем, минем чыпчыгым оядан җиргә төште, кире ояга күтәреп бирче әле,- дигән.

- Минем вакытым юк, изге эшләрне эзлим, үземнең энәләремне үстерәсе бар,- диде керпе.

Шулай итеп, керпе үз юлын дәвам иткән. Изге эшләр эзләп барганда, аның юлында аркасына әйләнгән коңгыз очрый һәм аннан ярдәм сорый.

-Мине әйләндереп аякка бастыр әле, - диде ул.

Ләкин керпенең эше каты иде, ул аңа булышмады, алга таба юл тотты. Керпенең барлык кылган гамәлләрен өстән кара карга күзәтеп йөргән һәм керпегә әйтте:

-И, юләр керпе, син изге эшләр эзләп йөрисең, ә алар синең юлында инде ничә тапкыр очрады бит. Ә син аларның берсен дә күрмәден.

Шуннан керпе үзенең ялгышлыгын аңлады һәм каргага әйтте:

Әй, карга, мин чыннан да, үземнең хаталарымны аңладым.Кирәк чакта ярдәм кулы сузмаганмын икән.

Шушы көннән алып, керпе урмандагы бөҗәкләргә, хайваннарга ярдәм итә башлаган. Аның шушы изге гамәлләре өчен, берникадәр вакыт үткәч, керпегә куе, матур энәләр үсеп чыккан.

Шәрифуллина Мәдинә

*****

**Кышкы могҗиза**

Кыш озын, ә салкыннар каты булган бер шәһәрдә Илдар исемле малай яшәгән. Аңа нибары 12 яшь кенә иде. Шулай кечкенә булуына карамастан, ул инде утын да яра белгән, мичкә дә яга өйрәнгән. Илдар һәр иртә ишегалдына чыга, кар чистарта. Түземсезлек белән кар яуганын көтә. Кар бөртекләренең җиргә очып төшкәнен күзәтергә ярата. Аның өчен алар ниндидер тылсым көченә иядер сыман тоела.

Бервакыт, Яңа ел алдыннан, күк йөзен тыгыз соры болыт каплап алды, ә кичкә таба куе кар яуды. Илдар тәрәзә янында һавада биюче кар бөртекләрен күзәтеп торды. Ул аларның һәркайсы үзенең серен саклый кебек тоелды. "Менә бер генә сәгатькә булса да, кар бөртеге булырга иде,-дип уйлады ул,- дөньяның өстән нинди булуын карарга иде". Икенче көнне иртән Илдар капка төбендә кечкенә генә бер көчек тапты. Ул салкыннан калтырана, ләкин малайга шундый тугры күзләре белән карый иде, Илдар үтеп китә алмады. Ул көчекне өйгә алып керде, иске

одеялга төрде, җылы сөт салды. Көчек шунда үк йоклап китте, ә Илдар аны Акбай дип атарга булган.

Малай көн саен аның белән йөрде, командалар үтәргә өйрәтте, аның өчен ишегалдында кечкенә өй төзеде. Ә Акбай “дөрес җавап бирергә” өйрәнде. Илдарны мәктәптән каршы алды, аны салкын кичләрне җылытты. Ләкин беркөнне төнлә көчле буран купты. Илдар борчулы Акбай өрүеннән уянды. Көчек ишек төбендә чабып йөри һәм тышка чыгарга сорый иде. Малай башын күтәрде. Илдар тәрәзәдән башын тыгып, аның җуйды: якында гына, кар көртләре артында, калтыранган төлке шәүләсе күренә иде. Ул тәпиен күкрәгенә кыскан һәм ярдәмгә мохтаҗ иде. Илдар, бер дә уйламыйча, курткасын салды һәм фонарен алды да, урамга чыкты. Акбай янәшә йөгерде. Якынрак килгәч, малай төлкенең тәпие яраланганын һәм хәрәкәтләнә алмавын күрде. Ул аны сак кына күтәреп өенә алып керде. Илдар, әнисе белән, төлкенең ярасын эшкәрттеләр, ә Акбай, яңа кунакны саклагандай, янәшә ятты.

Иртән буран басылды. Төлке, үзен яхшырак хис итеп, сак кына урыныннан торды да ишек янына килде. Илдар ишекне ачты да, төлке урамга чыгып китте.

Берничә көннән соң, бусагада балык ятканын күрделәр. “Бу төлкенең рәхмәтедер”,- дип елмайды әни. Кыргый җәнлекләр дә игелекле була беләләр. Шул вакыттан бирле Илдар тәрәзә артындагы кар бөртекләренә ешрак карый һәм: “Безнең һәрберебездә кечкенә бер могҗиза бар, тик аны күрә белергә генә кирәк”,- дип уйлый иде. Ә хәзер инде зур һәм көчле эт булган Акбай һәрвакыт янәшәдә була. Хәтта иң кырыс кышларда да йөрәк мәхәббәт һәм дуслыкны җылыта ала икәнен искә төшерә.

Салахова Зилә

*****

**Алинә һәм куянкай.**

Кышкы матур, салкын көнне Алинә мәктәптән өенә кайтып бара иде. Ул агач янында моңсу гына карап утырган йонлач куянны күрде. Кызга җәнлек кызганыч булып китте, чөнки кыш салкын һәм карлы иде, һәм аның аңа ничек тә ярдәм итәсе, ашатасы килде.

Алинә рюкзагыннан алма һәм икмәк кисэге алып, аларны куянга сузды. Куян тиз генә сыйны ашап бетерде һәм рәхмәт йөзеннән кызга карады.

Аннары кинәт кеше тавышы белән сөйли башлады.:

“Рәхмәт сиңа, мәрхәмәтле кыз! Мин үземне ашаткан кешегә күптән рәхмәт әйтмәкче идем. Син бик тә тәрбияле кыз икәнсең. Хәзер минем дустым бар!”

Алинә гаҗәпләнде, ләкин яңа танышуга шатланды. Алар бергәләп урман буйлап йөрергә, хайван эзләрен карарга һәм кар астында җиләкләр эзләргә киттеләр. Куянкай Алинәгә урман тормышын сөйләде,җәнлекләр телен дә бераз өйрәтте. Бик озак саф урман һавасын сулап йөргәннән соң,Куян кызчыкны өенә озатып куйды.Алар һәр ел саен очрашырга сөйләштеләр.

Ә кичен, йоклар алдыннан, Алинә Кыш Бабайга хат язды, яңа дустына Җылы өй һәм бик күп тәмле алма бүләк итүен үтенде.

Иртә белән Алинә уянды һәм тәрәзә төбендә «куян Дустым өчен» дип язылган кечкенә агач йорт күрде. Янәшәдә алма һәм кишер ята. Алинә үзенең теләге аның яхшылыгы аркасында тормышка ашканын аңлады.

Айнетдинова Азизә



# Фотоконкурс

**“ӘТИЕМ БЕЛӘН БЕРГӘ”**










# *Безнең йолдыз*

**Кыскача мәгълүмат:**
**Исеме:** Иванов Искәндәр Денис улы
**Туган көне:** 30 нчы декабрь
**Шөгыльләре:** шахмат уйныйм, компьютер, мотоциклләр яратам. Гимназиядә театр студиясендә шөгыльләнәм.

- **Син кайда, нинди гаиләдә тудың?**
Мин Минзәлә шәһәрендә артистлар гаиләсендә тудым. Гаиләдә мин - бердәнбер бала. Әтием- Денис Минзәлә драма театрында ут куючы, ә әнием Динара- артистка. Икесе дә сәнгать кешеләре, икесе дә Татарстан Республикасының атказанган артистлары.
- **Нинди балалар бакчасына йөрдең?**
Минзәләнең беренче балалар бакчасына йөрдем.
**-Беренче тапкыр нинди конкурста катнаштың?**
Беренче тапкыр районкүләм Габдулла Тукай бәйгесендә катнашып беренче урын алдым. Шуннан башлап бер бәйгене дә калдырмый катнашып барам.
- **Син бик күп бәйгеләрдә катнашасың, нинди грамота, дипломнарың бар?**
- “Җәлил укулары” халыкара әдәби бәйгедә бик күп тапкырлар катнашып килдәм. Берничә ел рәттән 2 нче 3 нче дәрәҗә дипломы белән бүләкләндем. Быел да Муса Җәлилнең “Табут” шигырен сөйләп өченче урынга лаек булдым. “ТАТАР СҮЗЕ” V нче Халыкара нәфис сүз телевизион бәйгесендә, 8-13 яшьлек катнашучылар арасында “Шигърият” номинациясендә Зиннур Насыйбуллинның “Татар теле” әсәрен яттан сөйләп, җиңүче булдым, 2 нче дәрәҗә диплом һәм 45 меңлек сертификат белән бүләкләндем.
Минем район, республикадан тыш, хәтта Рәсәй грамота, дипломнарым да бар.

- **Сине конкурсларга кем әзерли, кем белән шөгыльләнәсең?**
- Мин конкурсларга әни белән әзерләнәм. Әтием музыка һәм видео белән булыша. Әтием, әлбәттә инде, минем әсәрләрне сөйләвемне тыңлап, үзенең төпле



фикерләрен дә җиткерә. Әти-әниемнең киңәшләрен тыңлыйм, алар һәрвакыт миңа ярдәмгә килергә әзер.

- **Киләчәккә планнарың нинди?**

Планнарым зур... Минем юрист буласым килә.

- **Нинди конкурска әзерләнәсең?**

Галиәсгар Камал театры бинасында 8 нче халыкара Җәлил укулары бәйгесенә йомгак ясалды. Конкурска 40 меңнән артык гариза кабул ителгән, финалга 490 кешенең эше сайлап алынган. Шуларның 112 - җиңүче. Мин 4 ел буе бу бәйгедә катнашып килдәм һәм һәрвакыт җиңүчеләр исемлегендә булуым мине бик куандыра. 2023 нче елда 3 нче урын, 2024 нче 2 нче урын, 2025 нче елда 2 урын һәм 2026 нчы елда 3 урынны яуладым.

Искәндәр! Сине бу уңышларың белән котлыйбыз. Киләчәктә дә конкурсларда катнашып, зур уңышларга ирешүенә өметләнеп калабыз.



# Гимназия сулышы




Өстәмә белем бирү педагогы, Рөстәм Муллин исемендәге “Сәяр” балалар театры һәм киностудиясе җитәкчесе Ленар Газинур улы Миннемуллин "Мәдәнияттәге казанышлары өчен" мактау күкрәк билгесе белән бүләкләнде. Күпкырлы шәхес, талантлы Ленар Газинур улына алга таба да уңышлар телибез. Алдагы көннәрдә гимназиябезне танытып, туган телебезне үстереп яшәргә һәм эшләргә язсын!



4-А сыйныфының «Созвучие» вокаль ансамблен котлыйбыз! Безнең яшь артистларыбыз Бөтенроссия вокаль һәм хор коллективлары конкурсының республика этабында III дәрәҗә лауреат булдылар! Бу җитди казаныш — мондый дәрәҗәдә чыгыш ясау һәм жюриның югары бәясен алу. Балалар күрсәттеләр: көйле ансамбль яңгырашы; артистлык һәм эмоциональлек; хезмәт сөючәнлек һәм музыкага тугрылык. Коллектив җитәкчесе Хәкимова Елена Николаевнага әзерлек өчен, шулай ук эти — әниләргә ярдәм күрсәткәне өчен чын күңелдән рәхмәт белдерәбез! Сезнең белән горурланабыз, «Созвучие»! Бу бүләк яңа иҗади җиңүләргә баскыч булсын



Бүген Арча районының Яңа Кырлай авылында төбәкара "Аулак өй -көрәш" проектының финал ярышлары узды. Финалга Минзәлә гимназиясе һәм Татар Мөшегесе урта мәктәбенең җыелма командасы чакыру алды. Укучылар, финал ярышлары алдыннан, Габдулла Тукайның туган авылы Кушлавычта катнашкан "Тукаевлар музей йортында" экскурсиядә булдылар, бик күп кирәкле һәм кызыклы мәгълүмат белән таныштылар. Чөнки финал ярышларының темасы да Г.Тукай иҗатына багышланган иде. Укучылар Г.Тукайның әсәрләрен яхшы белүләрен исбатлап, җиңүче исеменә лаек булдылар һәм "Сәләт" лагерына юллама белән бүләкләнделәр. Укучыларны зур уңышлар белән котлыйбыз һәм горурланабыз.

***

Гимназиянең "Яшьлек" газетасы журналистлары, бүгенгесе көндә Казанда нефть, химия һәм нанотехнологияләр институтында белем алучы, 2025 нче елда гимназияне алтын медальгә тәмамлаган укучыбыз Фаррахова Камилә белән очраштылар. Камилә югары уку йортында уку шартлары, институтка керү өчен нинди

фәннәрдән бердәм дәүләт имтиханнары тапшырырга кирәклеге турында укучыларга җиткерде. Ул үзе химия фәне буенча бердәм дәүләт имтиханыннан 99 балл җыйган иде. Югары уку йортына керү өчен тырышып укырга, олимпиадаларда катнашырга кирәклегенә аеруча тукталды. Яшь журналистлар үзләрен кызыксындырган бик күп сорауларга җавап алдылар.




***

Шушы көннәрдә гимназиябездә Казан дәүләт энергетика университетының (КДЭУ) 5 курс студенты, чыгарылыш сыйныф укучысы И.Хәбиров белән очрашу узды. Җылы һәм формаль булмаган шартларда ул укучылар белән югары уку йортына керү тәҗрибәсе, республиканың әйдәп баручы университетларының берсе булган КДЭУда уку үзенчәлекләре, энергетика югары уку йортында белем алу



***

Түбән Суык - Су авылында "Алга"спорт комплексында" ТР Бадминтон өметләре" турнирының зона этабы - 1 тур узды. Ярышларда Минзәлә, Яр Чаллы, Түбән Кама, Тукай районы, Алабуга, Актаныштан 55 спортчы катнашты. 2 нче сыйныф укучысы Сафин Азамат үз яшь категориясендә 1 нче урынны алды. Молодец, котлыйбыз, шулай тотарга!

***




Беренче сыйныф укучылары Минзәлә шәһәре мәчетенә мавыктыргыч сәяхәт ясадылар. Бу вакыйга балаларны тәрбияләүдә мөһим этап булды, аларны ислам традицияләре һәм мәдәнияте белән таныштырды. Балалар изге урын эчендә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, архитектура үзенчәлекләре һәм мөселман традицияләренең символизмы турында күп кызыклы нәрсәләр белделәр. Дәрес дустанә атмосферада узды, һәр укучыга мәчеттә хөкем сөргән тынычлык һәм хөрмәт атмосферасын тоярга мөмкинлек бирде


.

***

Минзәлә мәчетендә мәдәни җомга клубы берләшмәсе һәм ветераннар советы белән берлектә әзерләнгән "Әйтер сүзем бар" рубрикасы кысаларында "Исра вә Мигъраҗ" дип исемләнгән кичә булды. Кичәдә гимназиянең 5 нче һәм 6 нчы Б сыйныфында укучы кыз балалары катнашты. Кичә барышында СВО геройлары белән очрашу, мәчеткә йөрүче волонтерларга рәхмәт хатлары тапшыру булды, батырларга багышлап язылган шигырьләр тыңланды, иң хәерле кичәләрнең берсе булган Мигъраҗ

кичәсе турында сөйләнде. Аны Р. К. Фәхретдинова алып барды һәм килгән укучыларга, кунакларга бик күп кирәкле, файдалы мәгълүмат җиткерде.



***

Туган як музеена сәяхәт. Гимназиянең 3Б һәм 4Б сыйныф укучылары, директор киңәшчесе Диләрә Наил кызы һәм милли мәсьәләләр буенча директор урынбасары Гузәлия Габделәхәт кызы җитәкчелегендә, беренче президентыбыз М.Ш.Шәймиевның туган көне уңаеннан, Актаныш районы Әнәк авылында урнашкан “Шәрип Шәймиев музей-йорты”нда экскурсиядә булдылар. Балаларга “Туган як музее” экскурсоводы, фәнни җитәкче Айгөл Айрат кызы президентыбызның балалык чорыннан бүгенге көнгә кадәр үткән тормыш юлы турында күп мәгълүмат җиткерде. Укучыларга бигрәк тә каралы - аклы телевизор, пластинкалы проигрыватель, чыбыклы телефон һәм зур коръән китабы ошады. Янадан укучылар “Бабайда кунакта” паркында ял иттеләр. Балаларга экскурсия бик ошады.



"Сабантуй" журналы әниләр көненә багышлап "Иң йөрәккә үткән хат", " Иң кызыклы хат формасы", "Иң матур кульязма" номинацияләрендә хат язу бәйгесе игълан итте. Бәйгедә һәр катнашучы үзенең әнисенә рәхмәт сүзләрен, күңел җылысын, матур теләкләрен хат рәвешендә җиткерергә тиеш иде. Гимназиянен 3А сыйныф укучылары: Галиева Язилә бәйгедә катнашучы сертификаты, ә Хәлиуллин Кәрим "Иң матур кульязма" номинациясендә җиңүче дипломы һәм истәлекле бүләк белән бүләкләнделәр. Иң ихлас хатлар журналның март санында урын алачак. 4А сыйныф укучысы "Сабантуй" журналы үткәргән "минем яраткан китапханәчем" конкурсында җиңү яулап, диплом һәм истәлекле бүләк белән бүләкләнде. Укучыларыбызны җиңүләре белән котлыйбыз!!!





Минзәлә шәһәрендә һәр ел саен үткәрелә торган “Уха” фестивале үтте. Безнең гимназиянең 8 нче сыйныф командасы уңышлы чыгыш ясап, 2 урынны яулады. Укучыларны җиңүләре белән котлыйбыз!!! Булдырдыгыз!!!